ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**07.09.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1646**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2010 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләүгә керешергә.
2. Шәһәр төзелешен зоналаштыру этапларын билгеләргә (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибен һәм срокларын билгеләргә (2 нче кушымта).
4. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында ( http:zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга .

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына карата
1 нче кушымта
07.09.2020 №1646

**Җирлек территориясенә карата шәһәр төзелешен зоналаштыру этаплары**

1. Торак зоналар.
2. Иҗтимагый-эшлекле зоналар.
3. Җитештерү һәм коммуналь зоналар.
4. Инженерлык-транспорт инфраструктурасы зонасы.
5. Авыл хуҗалыгы кулланышындагы зоналар.
6. Рекреацион билгеләнештәге зоналар.
7. Махсус билгеләнештәге зоналар.
8. Шәһәр төзелеше регламентлары кагылмый торган җирләр билгеләнми.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта
07.09.2020 №1646

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча эшләр үткәрү тәртибе һәм вакытлары**

| № т/б | Эш исеме | Срогы |
|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү турында карар кабул итү турында хәбәр бастырып чыгару | 10.09.2020 |
| 2 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын Комиссия тарафыннан әзерләү | 05.10.2020 кадәр |
| 3 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын комиссия тарафыннан тәкъдим ителгән техник регламентларның таләпләренә, җирлекнең генераль планына туры килү-килмәүгә тикшерү | 10.10.2020 |
| 4 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектының техник регламентларның таләпләренә, җирлекнең генераль планына туры килү-килмәве турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең бәяләмәсен әзерләү | 10.10.2020 |
| 5 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча җәмәгатьчелек фикер алышуы үткәрү турында карар кабул итү | 15.10.2020 |
| 6 | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү, гавами тыңлаулар беркетмәләрен әзерләү, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре турында бәяләмәләр әзерләү | 26.10.2020 дан |

| | | |
|---|---|---|
| 7 | «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар тәмамланганнан соң, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты җитәкчесенә җәмәгать фикер алышуларының нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә кушымталарын тәкъдим итү | 27.11.2020 |
| 8. | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре алып бару проектын Зеленодольск муниципаль районы Советына җибәрү турында карар кабул итү | 01.12.2020 |